ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 388-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.Н. Шәфигуллин, Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 388-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмmәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1847-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин,
М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелгән

**«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында**»;

2) 1 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяда:
а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында**»;
б) 1 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 статьяда:

а) 1 пунктта «эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының» сүзләреннән соң «(шул исәптән коммерциячел оешма белән идарә итү вәкаләтләрен мондый оешманың идарә органнары әгъзалары тарафыннан гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә коммерциячел оешманың идарә органнары әгъзаларының)» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктта «эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары» сүзләреннән соң «(шул исәптән коммерциячел оешма белән идарә итү вәкаләтләрен мондый оешманың идарә органнары әгъзалары тарафыннан гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә коммерциячел оешманың идарә органнары әгъзалары)» сүзләрен өстәргә;

5) 5 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 6 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

7) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) 5 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:

«$7^1$) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының шикаятьләрен карау кысаларында Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясындагы беренче – дүртенче өлешләрендә һәм $159^1$ – $159^3$, $159^5$, $159^6$, 160, 165 һәм 201 статьяларында каралган җинаятьләр, әгәр бу җинаятьләрне индивидуаль эшкуар аның тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм (яисә) аныкы булган, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында файдаланыла торган мөлкәт белән идарә итүгә бәйле рәвештә кылган булса, йә бу җинаятьләрне коммерциячел оешма белән идарә итү органы әгъзасы мондый оешма белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә йә коммерциячел оешма тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген һәм яисә башка икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә кылган булса, шулай ук Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясындагы бишенче – җиденче өлешләрендә һәм 171, $171^1$, $171^3$ – $172^3$, $173^1$ – $174^1$, 176 – 178, 180, 181, 183, 185 – $185^4$ һәм 190 – $199^4$ статьяларында каралган җинаятьләр турындагы эшләр буенча шикләнелүчеләр, гаепләнүчеләр һәм хөкем ителгәннәр хокукларын яклау максатларында Татарстан Республикасы чикләрендә урнашкан сак астында тоту урыннарында һәм җинаять җәзаларын мәҗбүри эшләр, кулга алу, иректән мәхрүм итү рәвешендә үтәүче учреждениеләрдә махсус рөхсәттән башка булырга;»;

8) 13 статьяда «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

9) 14 статьяда «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) нормаларын актуальләштерү һәм аны федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

Аерым алганда, «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 590-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба – Федераль закон) Россия Федерациясе субъектларындагы эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләргә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының шикаятьләрен карау кысаларында сак астында тоту урыннарында һәм җинаять җәзаларын мәҗбүри эшләр, кулга алу, иректән мәхрүм итү рәвешендә үтәүче учреждениеләрдә махсус рөхсәттән башка булу хокукы бирелә.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проекты белән Татарстан Республикасы Законының Вәкаләтле вәкилнең төп хокукларын беркетүче 8 статьясына тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим ителә.

Шулай ук Федераль закон нигезендә закон проекты белән Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына төгәлләштерү характерындагы үзгәрешләр кертелә.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, закон проектында Татарстан Республикасында Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил һәм Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфалары исемнәрен төзәтү каралган.

**«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына Татарстан Республикасында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасы исеме өлешендә үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.